ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

_________11.07.2022______ Балык Бистәсе штп. №__149пг_____

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының дәүләт һәм ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләрен һәм хезмәт коллективларын, шулай ук җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне объектив карауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе хакындагы Нигезләмәне;

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе составын;

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 14 июлендәге “Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау хакында”гы 162пг номерлы карарын;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 14 июлендәге “Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау хакында"гы 162пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 28 декабрендәге 255пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2021 елның 14 июлендәге "Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау хакында"гы 162пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2022 елның 10 мартындагы 71пг номерлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Р. Р. Җамалиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2022 елның 11 июлендәге
149пг номерлы карары
белән расланды

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе хакында Нигезләмә

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау буенча Комиссия (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләрен һәм хезмәт коллективларын (алга таба – хезмәткәрләр һәм хезмәт коллективлары) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм ведомство бүләкләре, шул исәптән Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты, Татарстан Республикасы министрлыкларының Мактау грамоталары, Татарстан Республикасы министрлыкларының Рәхмәт хатлары һ. б. (алга таба – дәүләт һәм ведомство бүләкләре), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре (алга таба – муниципаль бүләкләр) белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне объектив карауны тәэмин итү максатларында төзелде.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, бүләкләү һәм кызыксындыру тәртибен җайга салучы норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп функцияләре

2.1. Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт һәм ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү һәм бүләкләү турында җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләренең үтенечнамәләрен карый, тапшырылган документларның расланган таләпләргә һәм критерийларга туры килүен тикшерә;

хезмәткәрләрне, хезмәт коллективларын, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен дәүләт һәм ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү мөмкинлеге яки бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы

үтенечнамәләрне кире кагу яисә бүләк төрен үзгәртү турында нәтиҗә (бәяләмә) (комиссия утырышы беркетмәсе) әзерли, шул исәптән өстәмә соратып алынган документлар, белешмәләр һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча.

## 3. Комиссиянең хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен Комиссия хокуклы:

җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалар һәм вазыйфаи затлардан үз эшчәнлекләре өчен зарур булган бәяләмә чыгару өчен кирәкле белешмәләр һәм мәгълүматны, өстәмә документларны (оешмага нигез салыну датасы турында архив белешмәсен, оешма составында хезмәт куючыларның саны турында белешмә, белешмә-объективка, дисциплинар җәза куллану турында боерык күчермәсе, оешманың техник-икътисадый күрсәткечләрен) соратырга һәм алырга;

эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгына (алга таба – район Башлыгы) бәяләмә (комиссия утырышы беркетмәсе) әзерләргә һәм тапшырырга;

бүләкләү турында үтенечнамәләр юллаучы оешмалар вәкилләрен, гражданнарны тыңларга.

## 4. Комиссиянең эшен оештыру

4.1. Комиссия составы, шул исәптән рәисе һәм аның урынбасары, район Башлыгы карары белән раслана.

Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә һәм комиссия рәисе тарафыннан чакырыла, ул булмаганда – комиссия рәисе урынбасары тарафыннан. Комиссия утырышын аның рәисе үткәрә, ул юкта – комиссия рәисе урынбасары.

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.2. Комиссия карары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм тәкъдим итү сыйфатына ия. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карары комиссия рәисе (ул булмаганда – комиссия рәисе урынбасары), шулай ук комиссия сәркатибе һәм әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.3. Комиссия әгъзаларының берсен бүләкләү яисә кызыксындыру турындагы үтенечнамәне караганда, комиссия утырышында соңгысына катнашу рөхсәт ителми.

4.4. Законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән бүләкләү яки кызыксындыру турындагы документлар комиссия утырышы беркетмәсе белән бергә район Башлыгына тапшырыла.

4.5. Комиссия утырышлары өчен материаллар әзерләүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты һәм Башкарма комитетының оештыру бүлекләре башкара.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2022 елның 11 июлендәге
149пг номерлы карары
белән расланды

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Җамалиев Р.Р. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Вафина А.К. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешенү буенча) |
| Шелкова С.А. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы, комиссия сәркатибе (килешенү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Ногманова И.М. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Вафин Ф.М. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Кәримуллина Л.В. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ башлыгы (килешенү буенча) |
| Шакиров И.З. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ башлыгы (килешенү буенча) |
| Галиуллина А.Т. | - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУнең кадрлар мәсьәләләре буенча әйдәп баручы белгече (килешенү буенча) |
| Ситдиков И.М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсенең |

кадрлар буенча консультанты (килешенү буенча)

| | |
|---|---|
| Сәфәрова А.Ф. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге баш белгече (килешенү буенча) |
| Керженцева Г.Ф. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, “Балык Бистәсе районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУ директоры (килешенү буенча) |
| Хәмидуллина Н.К. | - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты һәм Башкарма комитеты хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы рәисе (килешенү буенча) |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2022 елның 11 июлендәге
149пг номерлы карары
белән расланды

Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе

1. Оешмаларның һәм җирле үзидарә органнарының хезмәткәрләрен һәм хезмәт коллективларын дәүләт һәм ведомство, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү һәм кызыксындыру турында үтенечнамәләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы (алга таба - район Башлыгы) исеменә тапшырыла. Район Башлыгы үтенечнамәне Комиссия турындагы Нигезләмә нигезендә алдан карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының (алга таба - Комиссия) дәүләт һәм ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль бүләкләре белән бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы үтенечнамәләрне карау буенча Комиссиягә җибәрә.

2. Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләр белән бүләкләүгә һәм кызыксындыруга тәкъдим итү турындагы үтенечнамә белән бер үк вакытта Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, норматив хокукый актлар нигезендә тиндәшле документлар да тапшырыла.

3. Бүләкләү һәм кызыксындыру турындагы документларны караганда түбәндәге таләпләр һәм критерийлар исәпкә алына:

тапшырылган документларны рәсмиләштерү дөреслеге;

кандидатның бүләкләү өчен ирешкән уңышлары һәм казанышларының характеры;

тармакта эш стажы;

түбәнрәк бүләктән югарырак бүләккә таба бүләкләү принцибы;

бүләкләү интервалы;

дисциплинар җәза булу-булмау;

хөкем ителгәнлекнең булу-булмавы;

салымнар түләү буенча бурычның булу-булмавы;

финанс-икътисадый күрсәткечләр (законнар нигезендә вазыйфаларга карата).

4. Бүләкләү һәм кызыксындыру өчен кандидатларны сайлаганда, барлык дәрәҗәдәге җитәкчеләрне бер үк вакытта тәкъдим итү рөхсәт ителми.

5. Бүләкләүгә кабат тәкъдим итү мөмкин:

яңа казанышлар өчен – алдагы бүләкләүдән соң 5 елдан да иртәрәк түгел;

оешмаларның кандидатурасы кире кагылган хезмәткәрләренә карата – комиссия тарафыннан әлеге карар кабул ителгән көннән бер елдан да иртәрәк түгел.